**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№946**
**12.02.2021**

«Белем. Казанышлар. Тәҗрибә»
XVIII балалар һәм яшьләр
иҗтимагый берләшмәләре һәм
ирекле отрядларының шәһәр
белем бирү форумын оештыру
һәм үткәрү турында

Башкарма комитетның 2019 елның 30 октябрендәге 5596 номерлы карары белән расланган 2020-2022 елларга муниципаль яшьләр программасын үтәү йөзеннән, балалар һәм яшьләр мохитендә иҗтимагый эшчәнлекнең абруен күтәрү, коммерцияле булмаган оешмаларның, яшьләр һәм балалар иҗтимагый берләшмәләренең талантлы лидерларын һәм җитәкчеләрен ачыклау, бүләкләү һәм аларга ярдәм күрсәтү максатларында

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсенә 2021 елның ноябрендә Яр Чаллы шәһәрендә «Белем. Казанышлар. Тәҗрибә» XVIII балалар һәм яшьләр иҗтимагый берләшмәләре, ирекле отрядларының шәһәр белем бирү форумын (алга таба – форум) оештыруны һәм үткәрүне тәэмин итәргә.

2. Расларга:

1) форум үткәрү турында нигезләмәне, 1 нче кушымтада каралганча;

2) форумны үткәрү буенча оештыру комитеты составын, 2 нче кушымтада каралганча;

3. Башкарма комитетның финанс идарәсенә форумны оештыру һәм үткәрү чыгымнарын финанслауны 2021 елга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетының «Яшьләр сәясәте» 07.07 бүлегендә (бүлекчәсендә) каралган акчалар хисабына 25 000,00 (егерме биш мең) сум 00 тиен күләмендә, 3 нче кушымтада каралганча тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.М. Хәлимовка, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы С.Р. Мулюковага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2021 елның 12 февралендәге
946 номерлы карарына
1 нче кушымта

«Белем. Казанышлар. Тәҗрибә» XVIII балалар һәм яшьләр иҗтимагый берләшмәләре ирекле отрядларының шәһәр белем бирү форумын үткәрү турында
нигезләмә

1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1. «Белем. Казанышлар. Тәҗрибә» XVIII балалар һәм яшьләр иҗтимагый берләшмәләре, ирекле отрядларының шәһәр белем бирү форумы (алга таба – форум) илне модернизацияләү, гражданлык җәмгыяте институтларын үстерү, мәдәниятара диалог процессына кушылган яшь гражданның позитив образын формалаштыру һәм популярлаштыру, шулай ук яшьләр һәм балалар иҗтимагый берләшмәләренә булышлык итү һәм аларның казанышларын күрсәтүгә юнәлдерелгән.

2. Форумның шәһәр этабын гамәлгә куючы булып Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсе тора. Конкурсны оештыру һәм үткәрү өчен составы Башкарма комитет карары белән раслана торган оештыру комитеты төзелә (алга таба – оештыру комитеты).

2 бүлек. Максат һәм бурычлар

3. Яр Чаллы шәһәре балалар һәм яшьләр иҗтимагый хәрәкәтен үстерүнең актуаль мәсьәләләре буенча фикер алышу өчен ачык мәйданчык булдыру форумның максаты булып тора.

4. Бурычлар:

1) Яр Чаллы шәһәре балалар һәм яшьләр иҗтимагый хәрәкәтенең актуаль мәсьәләләрен анализлау һәм алар буенча фикер алышу һәм аларны хәл итү юлларын эзләү;

2) Яр Чаллы шәһәре балалар һәм яшьләр иҗтимагый берләшмәләренең нәтиҗәле хезмәттәшлек итү һәм эшчәнлекне координацияләү формаларын үстерү;

3) Яр Чаллы шәһәре балалар һәм яшьләр иҗтимагый хәрәкәтен үстерүнең төп юнәлешләрен эшләү;

4) Яр Чаллы шәһәре балалар һәм яшьләр иҗтимагый берләшмәләренең уңай эш тәҗрибәсен ачыклау һәм тарату.

3 бүлек. Форумда катнашучылар, үткәрү урыны һәм сроклары

5. Форумда катнашучылар булып Яр Чаллы шәһәренең балалар һәм яшьләр иҗтимагый берләшмәләре, тимурчылык отрядлары һәм Россия укучылар отрядлары, мәктәп һәм студентлар үзидарә органнары тарафыннан форумда катнашу өчен делегат итеп билгеләнгән җитәкчеләр, лидерлар һәм активистлар, Шәһәр иҗтимагый оешмалар үзәгенең координацион советы әгъзалары тора.

6. Форумда катнашу өчен 2021 елның 1 ноябреннән соңга калмаган срокта https://forms.gle/ZExa7t1TjuZA45F39 сылтамасы буенча заяка бирергә кирәк.

7. Һәрбер балалар яки яшьләр иҗтимагый берләшмәсеннән форум делегатлары саны чикләнмәгән.

8. Форум 2021 елның ноябрендә «Нур» яшьләр үзәге» муниципаль автономияле учреждениесендә түбәндәге адрес буенча була: Яр Чаллы шәһәре. А. Рубаненко урамы, 2 (1/02) йорты.

9. Форумның программасы форумның максатларына һәм бурычларына ирешүгә юнәлтелгән чаралар комплексыннан гыйбарәт һәм үз эченә 4 тематик мәйданчыкны ала.

## 4 бүлек. Йомгак ясау

10. Форум резолюциясе форумның йомгаклау документы булып тора.

11. Форум резолюциясе барлык кызыксынучы яклар адресына Форум чаралары тәмамланган вакыттан башлап 10 көннән соңга калмаган срокта җибәрелә.

12. Катнашучыларга дипломнар бирелә.

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева